Республика Татарстан
СОВЕТ ШАРЛИАРЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
10 апрель 2025 ел

**КАРАР**
**№ 116**

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 32 статьясы нигезендә, Совет Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (1,2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 15 апреленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматын рәсми порталында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән (sarmanovo.tatarstan.ru), махсус мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан, түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга:

Шәрләрәмә авылы, Мәктәп урамы, 57 йорт.;
Сөлек авылы., Мәктәп урамы., 56 йорт.;
Кормаш авылы, Үзәк урамы, 21 йорт.

3. Карар халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль район
Шәрләрәмә авыл җирлеге
Совет рәисе Н.Н.Хуҗина

10.04.2025 ел, № 116нчы Шәрләрәмә
авыл җирлеге Советы карарына
1 нче кушымта

Шәрләрәмә авыл җирлегенең вәкиллекле органнарына депутатлар сайлау буенча Бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № п/п | Сайлау округы исеме | Сайлау округы чиге | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Шәрләрәмә № 1 | **Шәрләрәмә авылы**, Мәктәп урамы, №№ 1-93 йортлар; Елга урамы, йорт 1. | 50 |
| 2 | Шәрләрәмә № 2 | **Шәрләрәмә авылы**, Мәктәп урамы, №№ 2-86 йортлар. | 48 |
| 3 | Щәрләрәмә № 3 | **Шәрләрәмә авылы**, Елга урамы, №№ 2А-33 йортлар. | 50 |
| 4 | Шәрләрәмә № 4 | **Кормаш авылы**, Үзәк урамы, №№ 1-47йортлар; **Шәрләрәмә авылы**, Яшьләр урамы, №№ 1-10йортлар. | 50 |
| 5 | Сөлек № 5 | **Сөлек авылы**, Мәктәп урамы, №№ 1а-63А йортлар. | 41 |
| 6 | Сөлек № 6 | **Сөлек авылы**, Мәктәп урамы, 2А-82 йортлар. | 41 |
| 7 | Сөлек № 7 | **Сөлек авылы**, Мәктәп урамы, №№ 69-97, 84-94 йортлар. | 43 |